Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Корноухово авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 7**

Корноухово авылы 2021 елның 15 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге Советының 2014 елның 6 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге Советының 2014 елның 6 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 9 номерлы” карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 10 номерлы, 2015 елның 1июнендәге 12 номерлы, 2017 елның 22 августындагы 11 номерлы, 2019 елның 4июнедәге 6-2 номерлы, 2020 елның 4 февралендәге 2 номерлы, 2021 елның 7 декабрендәге 5 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пункттагы «беренче квартал беткәннән соң 15 майдан да соңга калмыйча, икенче квартал – 15 августтан да соңга калмыйча, өченче квартал - 15 ноябрьдән дә соңга калмыйча. Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә» сүзләрен алып ташларга.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Корноухово авылы, Совхоз урамы, 3 йорт; Чирмешан авылы, Советлар урамы, 21 йорт; Зюзино авылы, Үзәк урамы, 6 йорт; Наумово авылы, Наумово урамы, 3 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе муниципаль районыКорноухово
авыл җирлеге башлыгы Г.С Гумашян